Проект

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮТАЗЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР № 13

Ютазы ав. 28 августа 2026 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең 2024 елның 25 апрелендәге “Физик затлар милкенә салым турында”гы 5 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкәтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең 2024 елның 25 апрелендәге “Физик затлар милкенә салым турында”гы 5 санлы карарына (2024 елның 12 сентябрендәге 14 санлы, 2024 елның 11 ноябрендәге 18 санлы, 2025 елның 17 ноябрендәге 9 санлы, 2025 елның 1 декабрендәге 11 санлы, 2025 елның 23 декабрендәге 14 санлы карарлары редакциясендә) (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карарның 7 бүлекчәсенең 2 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 маддәсендәге 7 бүлеге нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 маддәсендәге 10 бүлегенең икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата 2 процент.».

1.2. 5 пунктның 5 абзацын карарларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Салым ташламалары салым ташламаларын куллану өчен нигезләр санына бәйсез рәвештә салым түләүче сайлаган һәр төр салым салуның бер объектына карата бирелә.»;

1.3. Карарның 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 маддәсе нигезендә үз көченә керә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә (Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталы" челтәр басмасында Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru (2013 елның 17 декабрендәге Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан бирелгән ЭЛ ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык) "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталын урнаштыру адресы буенча http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән кимендә бер ай узгач үз көченә

керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Ютазы авыл җирлеге башлыгы Л.М.Хәйруллина